“Диндә көчләү юк, ләкин өндәү һәм өйрәтү бар”
(Коръән Кәрим. 2-256)

# Ислам Нуры

№ 18 (646) 26 сентябрь, 2017 ел (1439, Мөхәррәм) Дини-иҗтимагый газета 1995 елдан чыга 12+

# КОТЛЫЙБЫЗ!



**15** сентябрьдә Татарстан Республикасы мөселманнарының Диния нәзарәте оешуга 25 ел тулды. Тантаналы юбилей җыелышында мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллин җитәкчелегендә Татарстанның бар мөселман дин эшлеклеләре — президиум әгъзалары, район имам-мөхтәсибләре, төбәк казыйлары катнашты.

ТР МДН 1992 нче елда мөселманнар корылтае карары белән оеша. Оешманың рәисе итеп мөфти Габдулла Галиуллин сайлана. 1998 елда III Корылтайда ТР МДН белән төбәк Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте берләшә, мөфтиятнең рәисе итеп мөфти Госман Исхаков билгеләнә. 2011-2013 елларда Илдус Фәизов мөфти булып тора, 2013 елдан бүгенгәчә ТР МДН рәисе, Татарстан мөфтие — Камил хәзрәт Сәмигуллин.

Камил хәзрәт истәлекле дата турында болай диде: “Монда утыручыларның күбесе шаһитләр генә түгел, әлеге вакыйгаларда үзләре катнашучылар. Иң мөһиме шул: без тулы канлы һәм бар көченә эшли ала торган мөфтият кенә төзеп калмадык, барыннан да бигрәк — аның бердәмлеген һәм мөстәкыйльлеген саклап килдек”. Ул Диния нәзарәтенең чирек гасыр дәвамында мәгариф, белем бирү, дәгъвәт, дини кануннарны үтәү буенча бердәмлек, социаль һәм мәгълүмати сәясәт өлкәсендә башкарган эшләре турында сөйләде. Бүген мөфтият эченә 1500дән артык теркәлгән мәхәллә һәм мәчет керә, ә бу исә Россия Федерациясендәге гомум мәчетләр санынннан дүрттән берен тәшкил итә. Җирле органнар 48 мөхтәсибәт һәм 9 казыят белән билгеләнгән. Голәмалар шурасы, Казыйлар шурасы һәм Аксакаллар шурасы төзелгән һәм алар уңышлы эшлиләр. Татарстан Диния нәзарәте бүгенге көндә мәхәлләләр саны буенча Россиядә икенче урында тора.

Үзенең чыгышын тәмамлап, мөфти Камил хәзрәт имам-мөхтәсибәтләргә дин өлкәсендә куйган хезмәтләре өчен рәхмәтен белдерде. “Без шактый озын юл үттек, әмма узасы юллар күп әле. Мөселман өммәтенә хезмәт итү өчен мөфтиятнең ныклы нигезе булдырылган. Бердәмлекне саклап, алдыбызда торган мәсьәләләрне уңышлы хәл итеп барабыз. Үзебезнең хезмәтебезне намуслы башкарып, Татарстанның чәчәк атуына һәм аның рухи үсешенә үзебездән лаеклы өлешебезне кертәбез”, - дип йомгаклады ул.

Мөфтинең мөхтәсибәтләр белән эшләү буенча урынбасары Мансур хәзрәт Җәләлетдин, нәзарәтне оештыру вакытындагы тарихи вакыйгаларда турыдан-туры катнашучы буларак, үзенең докладында үткән гасырның 90-нчы еллар турында шәхси хәтирәләре белән уртаклашты, бер уңайдан мөхтәсибләргә өстенлекле эш юнәлешләрен билгеләде һәм алар алдында мәсьәләләр куйды.

Мөфтинең мәгариф буенча урынбасары, Болгар ислам академиясе һәм Россия ислам институты ректоры Рәфыйкъ Мөхәммәтшин үзенең чыгышында Татарстанда дини мәгариф системасы барлыкка килү тарихына тукталды. “Бүген Татарстанда 700ләп мәчет каршындагы курслар, 9 мәдрәсә һәм ислам институты эшли, аларда 220 мөгаллим укыта һәм 4000нән артык шәкерт укый. Сентябрь аенда Болгар ислам академиясе ачылды”, - диде ул, бүгенге көнгә дә бәя биреп.

Пленумның көн тәртибендәге сораулар булып шулай ук “Хәләл” стандартлары Комитеты эшчәнлеге белән танышу да бар иде. Комитет җитәкчесе Марат Низамов ТР МДН һәм Комитет тырышлыгы белән Россиядә хәләл продукцияне җитештерү өлкәсендә Техник комитет барлыкка килүен әйтте. “Зәкят” Хәйрия фонды генераль директоры Ирек хәзрәт Җиһаншин исә үзенең чыгышында мөфтигә һәм мөхтәсибләргә социаль сәясәтне тормышка ашыруда актив катнашкан өчен рәхмәт белдерде. Аның сүзләренчә, тулы булмаган 2017 ел эчендә генә Фонд 45 авыру баланың дәвалау курслары өчен акча күчерде.

Диния нәзарәтенең юбилее уңаеннан үткәрелгән пленум утырышы үтелгән юлларга борылып карау да, алда торган бурычлар турында әһәмиятле фикер алышу чарасы да иде.

## Изге сәфәр

Хаҗ сәфәренә киткәннәр барысы да туган җиребезгә исән-сау әйләнеп кайтты. Быел “ТР МДН Хаҗ” программасы белән 1700 кеше хаҗ кылды. Алар арасында мөмкинлекләре чикле кешеләр дә — күрмәүчеләр, ишетмәүчеләр һәм арбадагы инвалидлар да бар иде. Иң яшь хаҗига 11, ә иң өлкәненә 88 яшь. Шунысы игътибарга лаек, оештыручылар хаҗ вакытында татар мохите булдырырга тырышкан: вәгазьләр, фарыз йолаларда озатып йөрү, лекцияләр, методик әдәбият, табибларның эше татар телендә башкарылган.



## Тарихка кайту

Халкыбызның милли, дини һәм мәдәни мирасы булган “Мозаффария” мәдрәсәсе бинасы, ниһаять, Татарстан Республикасы мөселманнарының Диния нәзарәте карамагына тапшырылды. 1888 елда төзелгән бу бина Казан шәһәренең Сара Садыйкова урамында урнашкан, моңа кадәр мөмкинлекләре чикле балалар өчен мәктәп вазыйфасын үтәгән. Капиталь ремонт ясалганнан соң мәдрәсә үзенең тарихи асылына кайтыр дип көтелә.



## Зәйләләр вәгазь тыңлый

14 сентябрьдә Зәй мөхтәсибәте зур чара оештырды. Хакимият вәкилләре, Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин, күрше-тирә районнарның имам-мөхтәсибләре, район халкы Зәй политехник колледжы бинасына җыелды. Районкүләм корбан мәҗлесендә Татарстан Республикасы мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин “Экстремизмга — юк” айлыгы кысаларында ислам диненең яхшылыкка, әдәп-әхлакка, күркәм гамәлләргә өндәүче дин булуы турында чыгыш ясады, динебездә террорчылыкка, экстремизмга урын булмавы турында әйтте. Зәй районының аксакал хәзрәте Сәгыйть хәзрәт Камалов, Чаллы шәһәре имам-мөхтәсибе Әлфәс хәзрәт Гайфуллин, Түбән Кама мөхтәсибе Салих хәзрәт Ибраһимов, быелгы хаҗдан алган хис-кичерешләре белән уртаклашкан Гамил хәзрәт Сәгыйров чыгышлары да күркәм вәгазьләргә нигезләнгән иде.



## Дәвамлы бәйрәм

Сентябрь ае — Корбан гаетенең дәвамлы булуы белән сөендерә, чөнки корбан ашлары әле дә дәвам итә. Пермь крае Барда районы Аклыш авылы мәчетендә дә шундый мәҗлес узды. Мәчетнең имам-хатыйбы Фидәил хәзрәт әйтүенчә, авылда 20 корбан чалынган, корбан чалучылар мәчеттә узачак корбан ашы өчен дә өлеш чыгарганнар. Мәҗлес бик күркәм узды: Коръән укылды, вәгазьләр сөйләнде, дога кылынды.



**(ТР МДН матбугат үзәге хәбәрләре)**

*Риза Фәхретдин*

# Гүзәл холык

◆ Тугрылык. Гүзәл холыкларның падишаһы — тугрылыктыр. Шуның өчен: “Балаларыңа тугрылык өйрәт, тугрылык исә аларга һәрбер өстенлекне өйрәтер”, — диләр. Тугры булган кеше — ышанычлы булыр.

◆ Үз хатаңны үзең тану. Бу сыйфат — өммәтләрнең, халыкларның югары күтәрелүенә дәлилдер.

◆ Кыю булу. Бу сыйфат — сүзне ачык сөйләү һәм күңелдәге фикерне югалып калмыйча, гади итеп бәян итүдән гыйбарәттер.

◆ Үз вазифаңны үзең белү. Бу сыйфат һәркемнең үзендә булырга, кемдер тарафыннан кисәтеп-көтеп тормаска тиеш.

◆ Хакыйкатьне күзәтү. Бу сыйфат эшләрнең тышкы ягын түгел, ә эчке мәгънәсен күзәтүдә чагыла.

◆ Вакытында эшләү. Бүгенге эшне иртәгә калдырмау — дөнья көтүнең беренче шартыдыр. Бер эшнең үз вакытыннан кичегеп эшләнүе бик күп эшнең бөтенләй эшләнми калуына сәбәп булуы мәгълүм.

◆ Үз уенда нык торучанлык һәм түземлелек. Бу сыйфат һәртөрле тыюларга каршы тору һәм үзе дөрес итеп санаган фикереннән кире кайтмауда ачык күренә.

◆ Үз-үзеңә ышану. Бу сыйфат беркемнән дә ярдәм көтмичә, фәкать үз-үзенә нык ышанган килеш бөтен авырлыкларны җиңеп алга баручы кешедә ачык чагыла.

◆ Намус. Кешенең бөтен кыйммәтлеге — намуслы булуда. Адәм балаларын фәрештәләр дәрәҗәсенә күтәрә торган нәрсә — намус булып, хайваннардан да түбән дәрәҗәгә төшерә торган нәрсә — намуссызлыктыр.

◆ Авырлыкка түзә белү. Бу сыйфат зур эшләрдә дә үзен-үзе яхшы тотып, салкын кан белән фикер йөртүдә ачык күренәдер.

# Колак салсаң, үкенмәссең

◆ Дүрт нәрсәне дүрт нәрсә белән беркетегез: иманнарыгызны — намаз, малыгызны — зәкәт, саулыгыгызны — сәдака, гыйлемне — язу белән.

◆ Артык мактаучыларның йөзләренә туфрак сибегез!

◆ Көнчелектән сакланыгыз, чөнки ут утын яки печәнне ничек яндырса, көнчелек тә изге гамәлләрне шулай ашый.

◆ Үзеңә әманәт ителгән нәрсәне иясенә тапшыр, үзеңә хыянәт иткән кешегә хыянәт кылма!

◆ Әгәр эшләр үз кешеләренә тапшырылмаса, кыямәт буласын көтеп тор!

◆ Дөньяда комсыз булма, сине Аллаһ яратыр, кешеләр кулында булган нәрсәләргә кызыкма, сине халык яратыр.

# *Сөекле пәйгамбәребезнең сыйфатлары*

*Ий Аллаһка иман китергән бәндәләр! Аллаһтан куркыгыз хакыйкый курку белән, Аллаһка тәкъва булыгыз. Дөреслектә Аллаһ Тәгалә сөекле пәйгамбәребезгә әйтте:*

*“Аллаһ сиңа Коръән һәм хикмәт (ягъни Коръәнне аңлатып бирүче сөннәтне) иңдерде һәм белмәгәнеңне өйрәтте, Аллаһның рәхимлеге сиңа бик олуг булды” (Нисә, 113).*

*Аллаһ Тәгалә сөекле пәйгамбәребезне кешеләр иң түбән дәрәҗәгә төшеп барган вакытта җибәреп, һәлак булудан коткарды. Сөекле пәйгамбәребез әйтә: “Дөреслектә Аллаһ Тәгалә җир йөзендә яшәүче кешеләргә карады һәм кайбер Китап әһелләреннән башка бөтенесенә дә нәфрәте чыкты”.*

Шуннан соң Аллаһ Тәгалә шушы динсезлек караңгылыгын Үзенең илчесен җибәрү белән яктыртты:

“Аллаһ сезгә зикерне, ягъни ислам динен иңдерде, иман китереп изге гамәлләр кылучыларны динсезлек караңгылыгыннан яктылыкка чыгарыр өчен, Аның илчесе сезгә Аллаһның ачык аятьләрен укый” (Талак, 10, 11).

Шулай итеп, Аллаһ Тәгалә сөекле пәйгамбәребезне пакъ ислам дине белән кешеләргә үзенең рәхмәте итеп җибәрде. Аның холкы Коръән иде, ул беркайчан да үзе өчен үч алмады, үзе өчен ачуы беркайчан да чыкмады. Ләкин әгәр дә Аллаһ куйган чикләрдән кем дә кем чыкса, ул Аллаһ ризалыгы өчен ачулана иде. Ул беркайчан да алдамады, аның сүзе даими дөрес һәм хак булды. Әгәр дә ул берәр кем белән килешү төзесә, аны үтәде. Аның холкы йомшак булды. Ул юмарт иде, фәкыйрьлектән курыкмады. Тәкәбберлек, бозыклык кебек сыйфатлардан ерак булды, бер кешегә дә ләгънәт кылмады. Бер кайчан да начарлыкка начарлык белән җавап бирмәде, киресенчә, күпчелектә гафу итәргә тырышты. Ул сораучыны беркайчан да кире какмады, иң кимендә бирер әйбере булмаса, күркәм сүзләр белән җавап бирде. Башкалар белән мөгамәләдә кырыслык, усаллык сыйфатларыннан ерак булды. Ул беркемнең дә сүзен бүлми иде, иллә мәгәр хаклыкка каршы чыгучыны сүз белән яисә утырган урыннан китү белән тыя иде. Ул үзенең күршеләренең хакларын үти, кунакларны якты йөз белән каршы ала иде. Тормышының һәр мизгеле Аллаһка буйсынуда үтә иде. Ул һәрнәрсәдә яхшылыкны күрә иде. Әгәр дә ике гамәл арасыннан сайларга туры килсә, җиңел гамәлне сайлый иде. Ул кешеләрне юатырга һәм кыерсытылганнарга ярдәм итәргә ярата иде. Ул үзенең сәхәбәләрен ярата, четрекле мәсьәләләрдә алар белән киңәшләшә иде. Әгәр дә берәрсе югалып торса, аның турында борчыла иде, чирләп яткан кешенең хәлләрен белергә ашыга иде. Әгәр дә сәхәбәләр арасыннан берәр кем вафат булса, аны озатырга килә иде. Акланучының гозерен кабул итә иде. Хөкем иткәндә бөтен кеше аның каршында тигез иде. Аның сүзләре кыска булса да, тирән мәгънәгә ия иде. Ул туры килә торган урында шаярырга да ярата иде, ләкин аның мәзәкләре алдау һәм кимсетү дигән сыйфатлардан ерак иде. Ул кешеләр арасында иң рәхимлесе булды, бигрәк тә үзенең сәхәбәләренә карата юмарт иде. Мәҗлестә берәр кешегә урын җитмәсә, үзенең янында урын таба иде. Әгәр дә берәр сәхәбә белән урамда очрашса, үзе беренче сәлам бирә иде, әгәр дә берәр кем белән кул тотышып күрешсә, ул беркайчан да үз кулын беренче тартып алмый иде. Кешеләр арасыннан иң тыйнагы иде. Әгәр дә берәр мәҗлескә соңга калып килсә, мәҗлеснең түренә керми, якын-тирәдәге буш урынга утыра, башкаларга да шулай эшләргә әмер итә иде. Мәҗлестә һәрбер кешегә үзенең күңел җылысын бирә иде. Шуңа күрә сәхәбәләр бөтенесе дә үзләре турында: “Аллаһның илчесе башка кешеләр арасыннан мине күбрәк сөя,” - дип уйлый иде. Әгәр дә берәр кем үз йомышы белән сөекле пәйгамбәребез янына килеп утырса, ул килгән кешедән алдан торып китми иде. Фәкыйрьләрдән йөзен чөерми иде, бай-түрәләргә аларның байлыгы өчен юнәлми иде. Аллаһның гади нигъмәтләрен дә бөекли иде, беркайчан да ашаган ризык турында начар сүз әйтмәде, тәмле булса ашады, тәмсез булса калдырды. Ул уң кулы белән ашый һәм эчә иде, ашау алдыннан “бисмилләһ”, ашаганнан соң “әлхәмдү ли ләһи” дип әйтә иде. Ул үзенең сәхәбәләреннән аерылмый иде, аны күреп белмәүче кеше: “Кайсыгыз Мөхәммәд?” - дип сорый иде. Ул ашауда һәм киемдә исраф кылмады, чиста, ак киемне кияргә ятатты, даими рәвештә баш киемен кия торган булды, ун кулның чәнти бармагында көмеш балдак йөртте, якты йөзен куе сакал бизәде.

Аллаһ Тәгалә аны бөтен галәмнәргә Үзенең рәхмәте итеп җибәрде. Ул бөтен кешеләрне бу дөньяда һәм ахирәттә бәхеткә ирешү чараларына чакырды. Иң беренче ул тәүхидтән башлады. Һәм мөшрикләр аңа каршы чыктылар. Чөнки ислам дине аларның ышануларына, гореф-гадәтләренә туры килмәде. Алар сөекле пәйгамбәребезне төрле әйберләрдә гаепли башлады: “Син сихерче, мәҗнүн”, - дип мыскыл итте, ә бит моңа хәтле алар аны “садык, амин”, дигән сүзләр белән хөрмәт иттеләр.

Сөекле пәйгамбәребез “Раббыңның хөкеменә карата сабыр бул, гөнаһка чумганнарына һәм хаклыкны инкяр итүче кәферләргә иярмә!” (Инсан, 24) дигән Аллаһның әмерләренә буйсынып, сабыр итте.

Унөч ел Мәккәдә, мөшрикләрнең газапларына түзеп, тәүхидкә чакырды, шуннан соң Мәдинәгә күчеп хиҗра кылды, шуннан соң шушы бәрәкәтле урында гаделлеккә, чын мәхәббәткә, тигезлеккә нигезләнгән җәмгыять барлыкка килде. Аллаһ Тәгалә аңа төрле могҗизалар бирде, шуларның арасыннан туры юлга, тәүхидкә, гыйлемгә, күркәм әхлакка өндәүче Коръән иң бөегедер. Гомеренең ахырында, ул үзе яши торган заманда булган патшаларга, исламга өндәп хатлар язып җибәрде. Тарихчылар әйтүенчә, сөекле пәйгамбәребез үзенең гасырында яшәгән унбер патшага ислам динен кабул итүгә чакырып хат язган иде. Шуларның арасыннан иң бөекләре: Рим императоры — Хиракл, Фарис патшасы — Кесра, Мисыр патшасы — Мукаукас, Эфиопия патшасы — Наҗаша. Шуларның арасыннан кайберләре пәйгамбәребезнең язган хатын укыгач, ислам динен кабул итте, ә кайберләре көферлектә калды.

Аллаһ Тәгалә күп аятьләрдә безне, сөекле пәйгамбәребезне үрнәк итеп алып, гыйбадәттә, әхлакта, яшәү рәвешендә аңа охшарга чакыра, Аллаһ Тәгалә әйтә: “Сезгә Аллаһның илчесе күркәм үрнәк иде” (Ахзаб, 21).

Шуңа күрә, кадерле дин кардәшләрем, сөекле пәйгамбәребезгә иярик, аңа гыйбадәттә, күркәм әхлакта, яшәү рәвешендә охшарга тырышыйк!

Вә ләкин кемдер әйтергә мөмкин: “Без күпме тырышсак та, берничек тә пәйгамбәребезнең дәрәҗәсенә ирешә алмабыз. Чөнки ул Аллаһның илчесе иде”. Әйе, бу дөрес. Шуңа күрә сөекле пәйгамбәребез әйтә: “Саддиду”: ягъни кушкан әйберне камил дәрәҗәсенә җиткереп эшләгез, “каррибу”: ягъни әгәр дә камил дәрәҗәсенә җиткереп эшли алмасагыз, мөмкинчелегегез җиткән хәтле камиллеккә ирешергә тырышыгыз.

**Әбүбәкер хәзрәт Әбдиев,**
**Чаллының “Тәүбә” мәчете имам-хатыйбы**

*Дөнья әдәбияты җәүһәрләреннән*

# Йөрәк бабай һәм падишаһ

*(Хикәят. Төрекчәдән Фатих Кутлу тәрҗемәсе)*

ҖАҺИТ ЗАРИФОГЛУ

Борын-борын заманда, күп тә түгел, аз да түгел, бары берничә гасыр элек, бер авылда карт белән карчык яшәгән. Авыл халкы әйтмешли, бу авыл "сәһил" җирдә урнашкан. Ягъни кыш көннәрендә өйләргә суык бураннар, салкыннар керми икән. Кышын яхшы гына булса да, җәен бу якларда яшәп булмый, ди. Тын алгысыз, чиктән ашкан дымлы һавасында көч-хәл белән генә сулыш аласың. Ярар, болары калып торсын, тирә-якта һәрнәрсә саргаеп сула, терлекләргә ашарлык үлән дә калмый икән. Менә шунлыктан, тирә-як авыл халкы кышын авылга кайта, ә җәен авылларын ташлап җәйләүләргә чыгып китә икән.

Шушы авылда Йөрәк Хасан исемле танылган яшь егет яшәгән. Авылда шулай эндәшкәннәрме, әллә армиядән алып кайтканмы — билгесез. Еллар үткән саен бу турыда кызыксынучы да булмаган. Йөрәк Хасан яшь хатыны белән җәен — җәйләүдә, кышын авылда яшәгәннәр, тора-бара авылның нык тамырлы кешеләренә әверелгәннәр. Яшьләре егермегә, утызга... ниһаять, сиксәнгә җиткән.

Гел бертөрле тормыш, гел бер үк күченүләр. Ләкин күңелләрендә бернинди ялыгу, дөньяга карашларында бернинди үзгәреш булмаган. Йөрәк Хасан үзе дә, хатыны Айшә дә япь-яшь килеш, яхшы күңелле булып калганнар. Бу вакытларда алар инде сиксәненче яшьләренең язына керәләр.

Менә тагын җәйләүнең исе авылга тарала башлаган. Көннәрдән беркөнне иртә белән беренче төркем юлга чыга. Аларга баш булып, авылның иң кешелекле, чын мөселман кешесе бара. Йөрәк Хасан белән Айшә әби икенче төркемгә калалар. Айшә әбинең тыны кысыла. Я бу төркем белән, я башка төркем белән кузгалабыз дигәндә, бөтен авыл күченеп тә бетә. Авылда Йөрәк Хасан белән Айшә әби генә кала. Җитмәсә, бер-бер артлы авырып китәләр. Беркөнне икесе дә сәламәтләнеп аякка басканнар.

— Хатын, ни диярсең, иртәгә юлга чыгабызмы? - дип сораган Йөрәк Хасан.

— Иркәем, — ди Айшә әби, - син ничек кушсаң, ничек кулай күрсәң, минем өчен иң яхшысы шул булыр.

Нинди генә эшкә бергә тотынырга уйласалар да, өйләнешкәнгә алтмыш биш ел вакыт узса да, бер-берсенең күңелен күрү өчен һәрвакыт шул рәвешле сөйләшеп, эшлисе эшләрен дә оныта торган булганнар. Менә бүген дә җәйләүгә бару турында сөйләшүләре исләреннән чыккан. Икенче көнне:

— Сөекле хатыным, ни диярсең, көннәр шундый җылынды. Бөркүлек безне харап итәчәк бит, юлга чыгыйкмы әллә? — диде ире.

— Иркәем, - диде янә Айшә әби, - син нәрсә дисәң, шул булыр.

— Һммм... бүген әзерләнеп бетәрбез, иншалла. Иртәгә иртәнге намаздан соң юлга чыгарбыз.

— Бик яхшы булыр иде, — диде хатыны.

Шулай итеп, өйләрендә тагын бер кич кундылар. Йөрәк Хасан уяну белән пышылдап кына:

— Хатын, - диде.

Әби шунда ук ишетеп, ләә иләәһә илләллаһ, дип яткан җиреннән торды. Тиз генә коедан су алып, аны комганга салды. Ләгән китерде. Хасан бабай җиңнәрен сызганды. Әби, изге бер эш эшләгән сыман, әкрен генә Хасан бабайның кулына комганнан су агызды. Аякларын юарга чират җиткәч, Хасан бабай комганны алып, аякларын үзе юды. Тураеп басуга, кулына сөлге тотып, карчыгы килеп җитте. Йөрәк Хасан ике кулын алга сузды. Әби исә, сөлгене җәеп, аңа бирде. Йөрәк Хасан хатынына изге теләк теләде:

— Хатын, Аллаһ синнән риза булсын! Тоткан әйберләреңне алтын итсен! Хәерле итсен! Сиңа теге дөньяда яхшы гамәлләрне генә юлдаш әйләсен! Алсу битле җан юлдашым!

— Ярый әле дөньяда син бар, Аллаһ синнән дә разый булсын. Сиңа лаек була алмыйм, картайдым, көчсезләндем, гаеп итмә.

— Әстәгъфирулла, бу нинди сүз? Бүтән ишетмим. Һыы...

Берсе алда, берсе бер аршын артта басып, ике рәкәгать сөннәт кылдылар. Башларын иеп, бераз тын тордылар. Соңыннан Хасан бабай күтәрелеп басты. Калын, егетләрчә мөбарәк тавыш белән камәт төшерде. Ул имам булды. Айшә әби — җәмәгать.

Алар укыган намаз!.. Тәннәре дә, рухлары да җиде кат күкләрдә, җәннәт бакчасы гөлестаннарында. Аларның йөрәк тибүләрен берәү күрә калса, әйтер иде: "Дөнья болар кулына тапшырылган, галәмнәр боларга бирелгән, ни кушсалар, шул булыр, бул дисәләр, булыр, җимерел дисәләр, җимерелер".

Намаз беткәч, башларын иеп, сүзсез генә тордылар. Кояш чыкканчы селкенмәделәр дә. Соңыннан Айшә әби ашны учакка куйды. Аннары, бисмилла әйтеп, болгата башлады. Аш пешкән арада, Йөрәк Хасан Аллаһка ялварды:

— Хакими мотлак, һичшөбһәсез, Син! Мал-мөлкәт синеке, мәгънә синеке. Мин гөнаһлыны кичер. Анам-атамны ярлыка. Айшә хатынымны кичер. Хаким, һичшиксез, Син! Мал-мөлкәт синеке, мәгънә дә синеке.

Утырып, бер савыттан аш ашадылар. Табын өстенә коелган ипи валчыкларын җыеп, бисмилла әйтеп, авызларына каптылар.

Бер сәгать тә үтмәгәндер, әйберләрен җыеп бетерделәр: бер кат юка түшәк, кечкенә генә йон чатыр; азык-төлек капчыгында бераз он, әз генә талкан, тархана, ясмык, бер уч ногыт борчагы, бер уч дөге; бер комган, бер кечкенә ләгән, берничә аш савыты, бер казан, берничә чокыр... Бар булган әйбер шулар. Әмма карасаң, шактый гына әйбер күренә. Таулар аша кем күтәреп барыр инде аларны? Һии, туктагыз әле: бер кечкенә дөяләре дә барлыгын онытканбыз! Бу әкият тә шул дөя аркасында килеп чыккан иде бит...

Йөрәк бабай белән Айшә әбинең бер ишәккәйләре булган. Ул аларга бик озак хезмәт иткән. Шулай беркөнне абзарга керсәләр — ишәк үлгән. Йөрәк бабай белән хатыны бик кайгырганнар, әмма, Ходайның тәкъдире, дип юанганнар. Йөк ташырга кирәк булгач, Ходай бирер әле, дигәннәр. Тагын бер ишәк сатып алырга ниятләгәннәр һәм Йөрәк бабай ат базарына ишәк алырга киткән, ләкин таба алмаган. Ни күрсен: башын иеп, кечкенә генә дөя басып тора икән, аңа берәү дә борылып карамый икән.

Дөякәйнең хуҗасы исә, аны һәркөн ат базарына алып килеп, сата алмыйча, кире кайта икән. Әлбәттә, монда бер хикмәт бардыр, беркөнне сатып алучы табылыр әле дип, бер дә кайгырмыйча алдына ашарына куя икән.

Һи, әллә бу әкияттә бер начар кеше дә юкмы? Болай булмас кебек күренә. Һәркем яхшы, һәркем канәгать, хәтта үлем килә калса да, аңа буйсынып, ризалык белән каршы алачаклар. Ләкин тукта әле! Әлбәттә, ниндидер хикмәт булачак...

***(Дәвамы бар)***

## ӘДӘБИ СҮЗ

*Рәзинә Мөхияр*

### Менәр кыям

Бөеклеккә дәгъва итмим –
Аллаһ бөек.
Түбәнгә дә тәгәрәмим –
Танылыйм дип,
Лаек булсам, булмасам да,
Дан алыйм дип.

Һәр кешегә фарыз-тиеш
Гамәл үтим.
Әз булса да, яктылыкка
Өлеш кертим.
Җиребезгә тамчы эзем
Салып китим.

"Динем!" – димен,
"телем"!" – димен,
Янам, көям.
Мәңгелектә алар алда
Менәр кыям.
Динем, телем сулышын мин
Җанда тоям.

### Нишлисең бит

Нишлисең бит...
Шушы илдә тудык,
Нишлисең бит...
Шушы илдә тордык,
Дәһрилекләр бездә чәчәк атты,
Җаннар кара ташлар булып катты.

Чистарыну авыр, нишлисең бит.
Чистарыну кирәк, нишлисең бит...
Аллаһ юлы иң дөресе икән,
Юлларыбыз кыеш-мыеш киткән.

Нишлисең бит...
Җан чистарту авыр,
Нишлисең бит...
Җанга каннар савар.
Дөрес юлдан алга бару мотлак,
Ничә еллар яшәгәнбез йоклап.

### Ярдәм сорадык

Динсез чорда үстек, намазларның
Кирәклеген аңлый алмадык,
Авыр чакта зәңгәр күккә карап,
Аллаһыдан ярдәм сорадык.

Җаныбызда тойдык Аллаһыны,
Зекер итә генә белмәдек.
Намаз укып сәҗдәләргә киткән
Кешеләрне күреп үсмәдек.

Шөкер, Аллаһ, дөнья алышынды,
Асылыма кайтам, кабул ит!
Ничә еллар намаз укылмаган,
И Аллаһым, берүк гафу ит!

### Язмыш йомгагы

Язмышларның үз кануны,
Безнең теләктән тормый.
Туры юлдан барганда да,
Бер дә кызганып тормый.

Тәгәри язмыш йомгагы,
Тәгәри уңга-сулга.
Бәхетле булып яшәргә
Калмасак иде соңга.

Язмыш-тәкъдир бик күп алдан
Язылып куйган безгә,
Яхшы эшләр, изгелекләр
Кайтсын гел үзебезгә.

Яхшылыктан гел яктылык
Юлыбызны яктыртсын,
Изге гамәл, теләк-дога
Тәкъдирләрне агартсын.

*Гамьле әңгәмә*

# Һәрбер яшьнең үз хөкеме...



**Октябрь аенең башында Өлкәннәр көнен, алай гына да түгел, ункөнлеген рәсми төстә билгеләп үтү инде матур бер гадәткә әверелеп бара. Аллаһы Тәгалә насыйп итсә, иртәме-соңмы, картлык һәркемгә килеп җитә. Аны нинди гамәлләр белән каршыларга? Бүгенге җәмгыятьтә “аталар һәм балалар” проблемасы нидән гыйбарәт? Үзебезне кызыксындырган төрле сорауларга Чаллы шәһәренең имам-мөхтәсибе Әлфәс хәзрәт Гайфуллин белән әңгәмә корабыз, ул – бүгенге түребезнең кунагы.**

*— Әлфәс хәзрәт, соңгы елларда һәртөрле тантаналар, чаралар күбәеп китте шикелле. Көн дә бәйрәм, көн дә туй дигәндәй, кирәге-кирәкмәгәне бардыр. Мөселман кешесе өчен Корбан гаете, Ураза гаете кебек бәйрәмнәр олуг саналганын беләбез, ә калган бәйрәмнәр ни дәрәҗәдә әһәмиятле?*

— Әгуузу билләһи минәш-шәйтанир-раҗиим. Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим. Әлхәмдү лилләһи Раббил гааләмиин, әссаләтү үәссәләәмү галәә расулиһи Мухәммәдин вә галәә әәлиһи вә әсхәбиһи әҗмәгыйн.

Кайбер бәйрәмнәр, чаралар безгә күп нәрсәне искә төшерү өчен кирәк дияр идем. Шул ук Өлкәннәр көнен алыйк — карт кешеләргә хөрмәт-ихтирам һәркөнне кирәк, анысын барыбыз да беләбез шикелле, ә мондый ункөнлекләрдә аларга аерым игътибар күрсәтәбез, бүләкләр бирәбез икән — моның нинди зыяны булсын?! Аллаһы Тәгалә насыйп итсә, картлык барыбызга да килер, мондый чаралар шул хакта булса да искә төшерер... Көз һәм яз айларында шәһәр хакимияте зиратларга баруны оештыра, кешеләр каберләрне җыештырып, дога кылып, бераз булса да тәэсирләнеп кайталар. Бу гамәлләр кирәк, Пәйгамбәребезнең дә (с.г.в.): “Каберләрне күбрәк зыярат кылыгыз — ахирәтне искә төшерерсез”, дигән сүзләре бар. Сигезенче март көнне әниләрне, хатыннарны, апа-сеңелләрне, кызларыбызны игътибар күрсәтеп сөендерәбез икән, туган көннәрне бәйрәм итәбез икән — моның файдалы ягын күрү хәерле. Туган көн — шөкер итү көне. Әлхәмдү лилләһи, син исән-сау, шушы яшеңә җиткәнсең; туганнарыңны чакырсаң, дога кылып, вәгазь тыңлап утырсаң — нинди зыян. Иң мөһиме — әлеге бәйрәмнәрне шайтан туена әйләндермичә, үрле-кырлы сикермичә, әдәп белән үткәрергә кирәк.

*— Өлкәннәр турында сүз кузгатканбыз икән, җәмгыятебездә олы бер тап булып торган картлар йортын телгә алырга мәҗбүрмен. Күптән түгел шундый йортларның берсендә булырга туры килде, андагы әби-бабайларның байтагы яшьлекләрендә азып-тузып йөргән, эчкән, гаиләсен ташлап киткән кешеләр икәнен белү сискәндерде. Гомер көзендә балалары барлыгын искә төшергәннәр, тегеләре үз чиратында аларны бирегә китергән.*

— Без дә картлар йортына барабыз, сөйләшәбез. Төрлесе бар. Балалары хәтта зур-зур урыннарда эшләгәннәрнең дә әниләре бар анда. “Апа, балаларыгыз булгач, нишләп монда соң сез?” - дигәч, “Балаларыбыз җыйнаулап сөйләштеләр дә, әни, сиңа анда яхшырак булачак дип, монда китерергә булдылар”, - диючеләр бар. Ата-анасы ялгыз гына калгач, картайгач, зәгыйфьләнгәч, булган бөтен әйберне сатып, монда китереп куючылар да бар. Төп сәбәбе — динсезлек, әдәпсезлек, Аллаһының диненнән ерак тору, Аллаһтан курыкмау. Әле генә сез әйтеп үткәннәрнең дә ахыр чиктә картлар йортына килеп эләгү сәбәбе — диннән, тугры юлдан китү. Элекке китаплардан укып белүемчә, авылларда әгәр картлыгында ялгыз калган, ярдәмгә мохтаҗ кеше булса, халык аны үз өстенә алган, утынын ярган, ризыгын бүлешкән. Әлбәттә, болар барысы да имамның, мәхәлләнең эшчәнлеге булган, алар кайгырткан, алар күз уңында тоткан. Элек балаларны ташлап калдыру дигән нәрсә булмаган — аны туганнары, күршеләре, яки таныш булмаган кеше булса да асрамага алган. Чөнки моның артында Аллаһ кушкан гамәл һәм зур әҗер ята. Пәйгамбәребез хәдисендә әйтелгәнчә, бер җирлектә бер мәзлум кеше булып, беркем дә игътибар бирмәсә, бөтен авыл гөнаһлы саналган. Әгәр бер генә кеше булса да ярдәм кулы сузса, авыл өстеннән төшкән. Элек халык үзе белеп ярдәм иткән, әгәр бик зәгыйфь кеше булса, чиратлап караганнар. Менә бу чын мөселманча яшәү рәвеше. Бездә бүген дә шулай булырга тиеш тә соң, тик без моннан ерак әле. Бүген иң беренче чиратта үзебезнең балаларыбызга дин-әхлак тәрбиясе бирергә кирәк. Син бернәрсә дә белмәгән бала вакытта, зәгыйфь вакытта ата-ана сине карап, ашатып, эчертеп торган. Беркөн килеп әти-әни үзе дә зәгыйфьләнә, картая. Инде син аларны тәрбияләргә тиеш. Аллаһы Тәгалә әйтә: “Ата-анаң көчсезләнгәч, хәтта уф та димә!” дип тыя. Әти-әниләр картайгач, аларны карап-тәрбияләп тору — балаларның бурычы.

*— Тирәлектә үзебез дә тап булабыз, табиблар да искәртә: бүген өлкән кешеләр арасында картлык чире — деменция, шизофрения белән авыручылар арткannan-арта. Моның сәбәбе нидә дип уйлыйсыз? Алар туган-тумачага, күрше-күләнгә “балалар мине карамый, ашатмый, тәрбияләми” дип зарлана, газетага хат яза, телевидение чакыртып мәшәләнә. Мондый очракларда янәшәдә булган якыннарына нишләргә?*

— Бүген кеше Аллаһны танымый, Аллаһтан курыкмый — дөньядан төшеп калудан курка. Әз генә авырлык булса да бөгелә, сабыр итә белми. Шул сәбәпле дә психик яктан авыруга дучар була. Сабый бала бик бәләкәй чакта нишләгәнен аңышып бетерми бит, авырлык китергән мәлләре дә була — шуның шикелле, картайган кеше бала хөкеменә кайта, кирәкмәгән сүзләр дә сөйләргә мөмкин. Әлбәттә, карап-тәрбияләп торган кешегә җиңел түгел. Бу очракта ул бары тик сабырлыкка гына таяна ала. Чыннан да, мондый хәл күпләрнең башыннан үтә: әби-бабай, авызында ризык булган килеш тә килгән-киткәнгә “ашатканнары юк, караганнары юк” дип зарланырга мөмкин. Карап торганда, ул сүзләрне бик акыллы, төгәл, ышандырырлык итеп әйткән шикелле. Гомерендә бер тапкыр килеп, шундый сүзләрне ишеткән кеше урамга чыгып, “менә, аналарын карамыйлар икән...” дип гайбәт таратырга тиеш түгел. Гайбәт тарата икән, Аллаһ каршында үзе җавап тотачак. Мондый авыруларның балаларына, әйткәнемчә, сабырлык кына юлдаш була ала. Чит-ят сүзләргә карамыйча, борчылмыйча, ата-анаңны карап-тәрбияләп тор, ахирәттә әҗер-савабын алырсың. Нишлисең, адәм баласында бөтәннән кимчелек, яман эзләү чире бар инде, кеше күзендәге чүпне күрә ул, үзенең күзендәге бағананы күрми... Никах, исем кушу мәҗлесләрендә менә шушылар хакында, хакларны үтәү — ана хакы, бала хакы, күрше хакы турында күбрәк сөйләү хәерле.

*— Дин юлына басканнан соң, ата-ананың каршылыгына очраган яшьләр бар, “Яулык бәйләп безне рисвай итеп йөрисең” дип зарланучы әниләр, намаз укыган баласына шикләнеп караган әтиләр бар...*

— Мондый четерекле хәлләр күп. Сәбәп — әти-әнинең денсезлегендә, үз тамырын, ата-бабаларының кем булуын аңламауда. Ата-бабалары иманлы, динле иде, аннан соң килгән буын 70-80 ел эчендә тамырлардан аерылды. Бүген диннән читләштерү өчен нинди генә хәйләкәр юлларга басмыйлар: хиҗап кигән, яулык бәйләгән хатын-кызны террорчы, шәһид дип күрсәтеп, аларга нәфрәт белән карауга ирешергә телиләр. Әлбәттә, ата-ана куркуга төшә. Баласының дингә басуына башта сөенә, бераздан ни сөенергә, ни көенергә белми, аннан көенә, үз баласы белән көрәшә дә башлый. Бала ата-анасына рәнҗергә тиеш түгел, хикмәт белән, сабыр гына аңлатырга тиеш. Нинди генә булса да, ул синең әти-әниең, аларны хөрмәт итәргә, тыңларга кирәк. Тик әйткән сүзләре шәригатькә каршы килә икән, намаз укыма диләр икән — бу очракта аларны тыңлау урынсыз. Әле формалашып та җитмәгән яшь кешегә мондый очракларда бик күп көч, сабырлык кирәк, әмма Аллаһы Тәгалә тугры юлда калырга үзе ярдәм итә дип уйлыйм.

*— Мәктәпләрдә татарча укыту, гомумән, татар теленә кагылышлы сораулар республикакүләм көнүзәк мәсьәләләрнең берсе. Баласын туган телдә укытуга теше-тырнагы белән каршы торган ата-аналар бихисап. Ана телен белмәгән бала киләчәктә динен, иманын саклаучы була алырмы соң, әллә башка милләтләр эчендә эреп югалуга дучар булырмы?*

— Тел бетү — милләтнең бер афәте, тел белән бергә аның гореф-гадәтләре дә югала. Элек әби-бабайларыбыз телне дә, динне дә сакладылар, нинди генә авыр вакытларда да югалтмадылар. Ислам дине күп нәрсәне саклады дибез, әмма ул телдән аерылгысыз бит. Бүген дингә туган телен аңламаганнар да килә, алар үзләренең бабаларын, тарихны, галимнәребезне белмиләр, дингә дә яңачарак карыйлар. Ислам динендәге башка милләт үзенчәлекләренә тартылалар. Менә бу хәл бераз кискенлекләр китереп чыгара. Безгә әдәп-әхлак мәсьәләсендә дә, тел мәсьәләсендә дә бик нык эшләргә кирәк әле. Туксанынчы елларда дилбегәне кулдан ычкындырдык, заманга ияргдек. Шуның җимешләрен татыйбыз хәзер, картлар һәм яшьләр арасында бәйләнеш юк — дини тәрбия булмагач каян килсен ул. Запас бетте — авыр чорларны күргән әби-бабайлар үлеп беттеләр. Безнең буынга эләккән әби-бабайлар башкачарак, заманчарак инде.... Тәрбия гаиләдә булырга тиеш. Чөнки баланы мәктәп тәрбияләми, ул ата-ананың вазыйфасы. Дәүләт тарафыннан татар теленә йөз белән борылу бик яхшы, инде тәрбиягә дә борылу кирәк булыр...

***Әңгәмәдәш — Айгөл Әхмәтгалиева.***

**Нәшире**
**Иршат Гыйльметдин улы**
**ШӘЙХАТТАР**

**Баш мөхәррир**
**Айгөл Абдуллина**

**Тел.:** (8552) 70-51-09
**Факс:** (8552) 70-51-45

* * *

**Оештыручылары:**
Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан җөмһүрияте мөселманнары Диния нәзарәте, “Ислам нуры” дини эшмәкәрлек Үзәге

Газета мәкаләләрен күчереп басканда аларның “Ислам нуры”ннан алынганын күрсәтү мәҗбүри.

Редакциягә килгән язмалар игътибар белән өйрәнелә, рецензияләнә. Хатлар газетага әзерләнгәндә авторларның стиле саклана.

**Хатларны 423802, Чаллы Үзәк ур., 72 адресы буенча юллау кирәк.**

**Электрон хатлар өчен:**
**e-mail: islamnury@mail.ru**

Мөселманнар арасын бозуга, үзара каршылыкларга китерергә мөмкин булган хатлар, шикаятьләр газетада басылмый.

Дин-шәригать мәсьәләләренә кагылышлы язмалар, укучы сораулары Татарстан Диния нәзарәтенең баш казые, Чаллы төбәге мөхтәсибәтенең гыйльми Советы тарафыннан өйрәнелә һәм аларга җавап бирелә.

Россия Федерациясе матбугат, телерадиотапшырулар һәм массакүләм коммуникацияләр Министрлыгының Идел буе төбәкара территориаль идарәсендә ПИ № 7-0997 саны белән 2001 елның 15 ноябрендә теркәлде.

“Роспечать” агентлыгы каталогына кертелгән, язылу ел әйләнәсендә Россия Федерациясе буенча алып барыла.

Айга ике мәртәбә чыга.

**Тиражы 1100.**

**Индексы 54149**

* * *

Хөрмәтле укучыбыз!

Газетабызны укып чыккач, аны туганнарыгызга, танышларыгызга, яки башка мөселманнарга тапшырсагыз иде. “Ислам нуры”ның һәр саны кулдан-кулга күчеп динебезне таратырга ярдәм итсә иде. Әмин.

Шулай ук укучыларыбыз, Коръән аятьләре язылу сәбәпле, газетаны кирәкмәгән урыннарга ташлаудан сакланырлар дип ышанабыз.

* * *

Газета компьютерда җыелды, офсет ысулы белән “Ислам нуры” басмаханәсендә басылды.

Нәшир һәм редакция адресы:
**423802, Яр Чаллы,**
**Үзәк урамы, 72**

**Басарга кул куелды:**
**график буенча**
**26 сентябрь 16 сәг.**
**фактта 26 сентябрь 16 сәг.**

**Бәясе ирекле**